**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 3 и 5 Закона Республики Татарстан «О налоге на имущество организаций»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 июня 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 ноября 2003 года № 49-ЗРТ «О налоге на имущество организаций» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 июля 2010 года № 51-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 11; 2010, № 7 (II часть); 2011, № 5, № 8 (I часть); 2012, № 2, № 6 (I часть); 2013, № 3, № 6 (II часть), № 10, № 12 (I часть); 2014, № 10 (I часть); 2015, № 6 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2017, № 1 (часть I), № 17 (часть I), № 50 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 1 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 9 части 1 статьи 3 изложить в следующей редакции:

«9) садоводческих или огороднических некоммерческих товариществ, а также некоммерческих организаций, созданных до 1 января 2019 года гражданами для ведения садоводства, огородничества или дачного хозяйства, – в отношении имущества, являющегося имуществом общего пользования в соответствии с Федеральным законом от 29 июля 2017 года № 217-ФЗ «О ведении гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»;»;

2) в статье 5:

а) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2) с 1 января 2019 года пункты 10, 14, 15 части 1, пункт 9 части 2 статьи 3 настоящего Закона;»;

б) пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) с 1 января 2020 года пункт 10 части 2, пункт 2 части $2^1$, пункт 2 части 3 статьи 3 настоящего Закона;»;

в) пункт 8 изложить в следующей редакции:

«8) с 1 января 2022 года пункт 9 части 1, пункты 8, 11 – 13 части 2 статьи 3 настоящего Закона.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2019 года.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
30 июня 2018 года
№ 45-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) “Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гомуми файдаланудагы мөлкәт булып торган мөлкәткә карата гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яисә дача хуҗалыгы алып бару өчен 2019 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләре, шулай ук коммерциягә карамаган оешмалар;”;

2) 5 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) 2019 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 10, 14, 15 пунктларын, 2 өлешенең 9 пунктын;”;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) 2020 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 10 пунктын, $2^{1}$ өлешенең 2 пунктын, 3 өлешенең 2 пунктын;”;

в) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8) 2022 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын, 2 өлешенең 8, 11 – 13 пунктларын.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 июнь
№ 45-ТРЗ